ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ТУТАЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

КАРАРЫ

2021 ел, 7 июнь №26

Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Тутай авыл җирлегенең Россия Федерациясе дәүләт урман фонды җирләренә кермәгән һәм физик һәм юридик затларның хосусый милкендәге җирләргә яшел утыртмаларны кисү тәртибе турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Урман кодексы, “Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, “Әйләнә-тирә мохитне саклау турында” 2002 елның 10 гыйнварындагы N 7-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының Тутай авыл җирлеге Советы карар кылды:

1.Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Тутай авыл җирлеге Советының 2021 елның 1 февралендәге 19 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы “Тутай авыл җирлеге” территориясендә, Россия Федерациясе дәүләт урман фонды җиренә кермәгән һәм физик һәм юридик затларның хосусый милкендәге җирләренә кермәгән яшел үсентеләр кисү тәртибе турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

3.2 пунктта «рөхсәт» сүзеннән соң «, авыл җирлеге башкарма комитеты тарафыннан бирелгән» сүзләрен өстәргә.»;

3.3 пунктта «Россия Федерациясе» сүзләреннән соң «(авария хәлләренә бәйле очраклардан тыш)» сүзләрен өстәргә;

3.7 пунктта «рөхсәт ителергә мөмкин» сүзләрен «рөхсәт ителә» сүзенә алмаштырырга;

3.8 пунктта «акт» сүзеннән соң «комиссия тикшерү.» сүзләрен өстәргә.

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Тутай авыл җирлеге Башлыгы Н.М.Насретдинова.